**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3885**
**29.07.2019**

«Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» шәһәр конкурсы үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең тотрыклы эше һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру максатында, Башкарма комитетның 2017 елның 27 октябрендәге 6519 нчы карары белән расланган «2018-2019 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы кысаларында, шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) 2019 елның 6 августыннан 30 августына кадәр үткәрергә.
2. Расларга:
1) шәһәр конкурсы турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;
2) конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.
3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм аңа йомгак ясау чыгымнарын финанслауны шәһәр бюдетының «Торак-коммуналь хуҗалыгы» 05.00 бүлегендә («Төзекләндерү» 05.03 бүлекчәсе) каралган акчалар хисабына, 349 500 (өч йөз кырык тугыз мең биш йөз) сум күләмендә тәэмин итәргә.
4. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2019 елның 29 июлендәге
3885 нче карарына
1 нче кушымта

«Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә»
шәһәр конкурсы турында
нигезнамә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) турында нигезнамә конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурс ел саен Башкарма комитет карары белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

3. Конкурсның оештыручысы булып Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (алга таба – идарә) тора.

4. Конкурс территориаль иҗтимагый үзидарә эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, халыкның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыруда эшлекле һәм социаль активлыгын үстерүгә һәм стимуллаштыруга, йорт яны территорияләрен карап тоту, төзекләндерү һәм яшелләндерүдә халык инициативасын үстерүгә, халыкны торак фонд сакланышын тәэмин итү эшендә катнашуга җәлеп итүгә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү өчен уңайлырак шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

5. Конкурсның бурычлары:

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә эшчәнлекне аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашыра торган территориаль иҗтимагый үзидарәләрне (алга таба – ТИҮ) ачыклау;

- уңай эш тәҗрибәсен берләштерү һәм тарату.

## 2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

6. Конкурста катнашучы булып, Яр Чаллы шәһәре ТИҮнең конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявка) биргән актив әгъзалары (алга таба – Катнашучылар) тора.

7. Конкурста катнашу өчен, Катнашучылар 2019 елның 5 августына кадәр Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенә түбәндәге документларны тапшыралар:

1) конкурста катнашуга заявка;

2) узган календарь ел һәм агымдагы елның беренче ярты еллыгы өчен ТИҮ һәм КФЙ Советының эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат (төрле

формада бирелә: видеоматериаллар, фоторәсемнәр, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан мәкаләләр тезмәсе);

3) ТИҮ һәм КФЙ Советының киләсе календарь ел өчен эш планы.

Заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң барлык конкурс материаллары конкурс комиссиясенә (алга таба – конкурс комиссиясе) тапшырыла.

8. Конкурсны оештыручылар конкурста Катнашучыларның ризалыгы буенча, тапшырылган конкурс материалларын массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм Интернет челтәрендә урнаштыру өчен файдалану хокукына ия.

9. Конкурс комиссиясенең составы Башкарма комитет карары белән раслана.

10. Конкурс комиссиясе:

1) конкурска тапшырылган материалларны карап тикшерә;

2) конкурста катнашуга заявканы кабул итү яки кире кагу турында карар чыгара;

3) конкурска йомгак ясый һәм җиңүчеләрне билгели.

11. Конкурс комиссиясе әгъзаларының өчтән ике өлеше утырышта катнашкан очракта, ул тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карары гади күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә. «Риза» һәм «каршы» тавышлар саны тигез (50%) булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

12. Конкурс түбәндәге очракларда үтмәде дип танына:

1) конкурста катнашуга заявкалар булмау;

2) конкурста катнашуга бер заявка керү.

## 3 бүлек. Конкурс критерийлары

13. Конкурс комиссиясе тапшырылган заявкаларны карап тикшерә һәм аларны биш баллы системада бәяли.

14. «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» номинациясе критерийлары:

1) ТИҮ, хакимият органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, иҗтимагый оешмалар чикләрендә яшәүче гражданнарның мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

2) хокук саклау оранннарына һәм ирекле халык дружиналарына җәмәгать тәртибен саклауда булышлык итү;

3) гражданнарның социаль якланмаган категорияләренә ярдәм күрсәтү буенча хәйрия акцияләре үткәрү;

4) балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү, спорт һәм балалар мәйданчыкларын тиешенчә карап тоту;

5) культуралы ял һәм физкультура-сәламәтләндерү чаралары үткәрү;

6) ял итү урыннарын җиһазландыру;

7) ТИҮдә яшәүчеләрнең үзешчән сәнгатен үстерү;

8) КФЙ Советы, йортлар буенча җаваплы затлар белән үзара нәтиҗәле эшчәнлекне тәэмин итү.

15. «Иң яхшы күп фатирлы йорт советы» номинациясе критерийлары:

1) йорт комитеты, «подъездлар буенча җаваплы затлар» булу, аларның халык белән йорт яны территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү, подъездларда чисталык һәм тәртип саклау эшендә актив катнашуы;

2) халык белән җыелышлар үткәрү һәм аларның карарларын үтәү;

3) балалар һәм яшүсмерләр белән эш оештыру, мәдәни-спорт чаралары үткәрү;

4) халыкның йорт яны территориясен төзекләндерүдә, яшел утыртмаларны карап үстерүдәге активлыгы;

5) йорт яны территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм карап тоту;

6) нигезсез сәбәп буенча, 90 нан артык көн өчен торак-коммуналь хезмәтләргә вакытында түләмәү очраклары булмау;

7) торак йортны (балконнарны, тәрәзә һәм ишекләрне, баскычларны, подвалларны) карап тоту.

16. «Үрнәк йорт» номинациясе критерийлары:

1) күп фатирлы йортның йорт эчендәге гомуми файдаланудагы бүлмәләрен тиешле санитар хәлдә карап тоту;

2) чүп үткәргечләрнең, баскыч урнашкан урыннардагы пыялаларның, яктылык чыганакларының, керә торган ишекләрнең, балкон киртәләренең техник торышын контрольдә тоту һәм аларның эстетик күренеше;

3) йортта яшәүчеләр көче белән балконнарны, подъезд яны участокларын яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү;

4) йорт отмосткаларын канәгатьләнерлек дәрәҗәдә карап тоту;

5) фатир, подъезд, йорт ишекләрендә номерлы билгеләр булу һәм аларның торышы;

6) йорт яны территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү;

7) мәдәни-массакүләм һәм спорт җиһазлары булу һәм аларның сакланышы;

8) балалар мәйданчыкларын, ял урыннарын җиһазландыру;

9) халыкның торак-коммуналь хуҗалыгы оешмаларына бурычлары.

17. «Иң яхшы подъезд» номинациясендә:

1) мәгълүмат стенды булу, фатир ишекләрендәге номерлы билгеләрнең торышы;

2) лифтларның техник һәм санитар торышы;

3) баскыч урнашкан урыннарны, гомуми файдалану урыннарын җыештыру;

4) чүп үткәргечләрнең, баскыч урнашкан урыннардагы пыялаларның, яктылык чыганакларының, керә торган ишекләрнең, балкон киртәләренең техник торышын контрольдә тоту;

5) чорма, подвал бүлмәләрен тиешенчә карап тоту;

6) стеналарны, тәрәзәләрне, керә торган ишекләрне, баскычларны чистарту, буяу һәм үрнәк дәрәҗәдә карап тоту;

7) йорт яны территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча эшләр (территорияне көнкүреш чүпләрдән чистарту, агач, куаклар утырту, клумба ясау);

8) яшел утыртмалар, мәдәни-массакүләм һәм спорт җиһазларының сакланышы;

9) балалар мәйданчыкларын, ял урыннарын җиһазландыру.

18. «Иң яхшы чәчәклек» номинациясендә:

1) чәчәклекнең гомуми композициясе;

2) яруслы булу;

3) киртәләр булу;

4) кече формалар (фонтаннар, фигуралар) булу;

5) чәчәклекләр булдырганда заманча дизайнер карарларын һәм алымнарын куллану, вертикаль яшелләндерүдән, яшел скульптурадан, инерт материаллардан (металл, агач, таш, керамзит һәм башка материаллардан) файдалану;

6) чәчәкләрне чәчәк ату дәвамлылыгы буенча сайлау, чәчәк композицияләренең оригинальлеге;

7) үсемлекләр үсү һәм чәчәк ату чорында чәчәклекләрне карап тоту.

19. Баллар суммасы конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан барлык критерийлар буенча билгеләнә, һәр Катнашучыга карата конкурсның йомгаклау билгесе куела. Бәяләү йомгаклары буенча Катнашучылар рейтингы төзелә.

20. Конкурс комиссиясе карары буенча, проектларны бәяләү өчен махсус белемле һәм квалификацияле экспертлар җәлеп ителергә мөмкин.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

21. Конкурс комиссиясенең карары конкурсның һәр Катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә һәм конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

22. Конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе тарафыннан ТИҮне – «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» шәһәр конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү өчен түбәндәге күләмдә грантлар бирү турында карар кабул ителә:

1) «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» номинациясендә:

- һәрберсе 30 000 сумлык өч беренче урын;
- һәрберсе 15 000 сумлык өч икенче урын;
- һәрберсе 10 000 сумлык өч өченче урын;

2) «Иң яхшы күп фатирлы йорт советы» номинациясендә:

- һәрберсе 15 000 сумлык өч беренче урын;
- һәрберсе 10 000 сумлык өч икенче урын;
- һәрберсе 7 000 сумлык өч өченче урын;

3) «Үрнәк йорт» номинациясендә:

- һәрберсе 5 000 сумлык өч беренче урын;

- һәрберсе 4 000 сумлык өч икенче урын;
- һәрберсе 3 000 сумлык өч өченче урын;

4) «Иң яхшы подъезд» номинациясендә:
- һәрберсе 4 000 сумлык өч беренче урын;
- һәрберсе 3 000 сумлык өч икенче урын;
- һәрберсе 2 500 сумлык өч өченче урын;

5) «Иң яхшы чәчәклек» номинациясендә:
- һәрберсе 4 000 сумлык өч беренче урын;
- һәрберсе 2 500 сумлык өч икенче урын;
- һәрберсе 1 500 сумлык өч өченче урын.

23. Конкурс йомгаклары «Чәчәкләр фестивале» шәһәр бәйрәмендә ясала.

## 5 бүлек. Грант бирү

24. Конкурс комиссиясенең карары нигезендә, Башкарма комитетның тиешле районнарының Территориаль иҗтимагый үзидарәләр Ассоциациясе белән «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» шәһәр конкурсында җиңүчеләргә грант бирү турында килешү төзи.

25. «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» шәһәр конкурсында җиңүчеләргә грант акчалары бирү турында килешү нигезендә, тиешле районнарның Территориаль иҗтимагый үзидарәләр Ассоциациясе шәһәр конкурсында җиңүчеләр белән ТИҮ рәисен һәм активын бүләкләүгә грант акчалары бирү турында килешү төзи.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 29 июлендәге
3885 нче карарына
2 нче кушымта

Конкурс комиссиясе
составы

1. Абдуллин Ринат Әзһәр улы – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе;

2. Зуев Илья Сергеевич – комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары;

3. Романова Әлфия Ринат кызы – комиссия секретаре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлеге башлыгы;

комиссия әгъзалары:

4. Альменеева Эльвира Емельяновна – Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары;

5. Әхмәтова Илвира Хәмзә кызы – җирле сәнәгать һәм коммуналь-көнкүреш предприятиеләре хезмәткәрләре оешмаларының Яр Чаллы шәһәр профкомы рәисе (килешенү буенча);

6. Зарипов Ленар Рәфыйк улы – Шәһәр Советы депутаты (килешенү буенча);

7. Кислов Александр Иванович – Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы;

8. Ситдыйков Салават Әнәс улы – Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы;

9. Николаев Олег Юрьевич – Шәһәр Советы депутаты (килешенү буенча);

10. Галимов Искәндәр Нургаләм улы – Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы;

11. Харисов Винер Хәмит улы – Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы;

12. Йосыпова Резида Мәхмүт кызы – «Жилой квартал» газетасының баш редакторы (килешенү буенча).

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова